| МИНИСТЕРСТВО СЕЛЬСКОГО ХОЗЯЙСТВА И ПРОДОВОЛЬСТВИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ ҺӘМ АЗЫК-ТӨЛЕК МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

2015 елның 8 сентябре г.Казань № 210/2 - пр

**“2015 – 2017 елларга Татарстан Республикасында ит өчен терлек үрчетүне үстерү” ведомство максатчан икътисадый әһәмиятле региональ программасын раслау турында**

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Россия Федерациясе субъектларының авыл хуҗалыгын үстерү буенча икътисадый әһәмиятле региональ программаларына ярдәм итүгә Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләр бүлү һәм бирү кагыйдәләрен раслау турында” 2010 елның 17 декабрендәге 1042 номерлы карары нигезендә

**б о е р ы к б и р ә м:**

1. Түбәндәгеләрне расларга:

1.1. “2015 – 2017 елларга Татарстан Республикасында ит өчен терлек үрчетүне үстерү” ведомство максатчан икътисадый әһәмиятле региональ программасын (алга таба – Программа) 1 нче кушымта нигезендә;

1.2. Программаны гамәлгә ашыруда катнашучы авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә, крестьян (фермер) хуҗалыкларына, индивидуаль эшкуарларга 2015 елда субсидияләр бирү тәртибен 2 нче кушымта нигезендә;

1.3. Программаны гамәлгә ашыруда катнашучы авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә субсидияләр бирү турында килешүне 3 нче кушымта нигезендә;

1.4. Программаны гамәлгә ашыруда катнашучыларга ит бирә торган мөгезле эре терлек токымнарының баш саннары милектә һәм (яки) аренда шартларында булу турында белешмәне 4 нче кушымта нигезендә;

1.5. Программаны гамәлгә ашыруда катнашучы авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә федераль бюджет акчалары исәбеннән бирелергә тиешле субсидияләр турында исәп-хисап белешмәнең формасын 5 нче кушымта нигезендә;

1.6. Программаны гамәлгә ашыруда катнашучы авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән бирелергә тиешле субсидияләр турында исәп-хисап белешмәнең формасын 6 нчы кушымта нигезендә.

2. Тапшырылган документларның дөреслеге, бюджет акчаларының максатчан кулланылуы өчен җаваплылыкны субсидияләрне алучыларга, агросәнәгать комплексы оешмаларының җитәкчеләренә һәм баш бухгалтерларына йөкләргә.

3. Бюджет алучы тарафыннан тапшырылган документларның дөреслеген тикшерүне һәм раслауны Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Татарстан Республикасы муниципаль районнарында Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәләре башлыкларына йөкләргә.

4. Терлекчелек тармакларын үстерү бүлеге башлыгы урынбасары С.М. Нигъмәтҗановка, инвестицияләр сәясәте һәм максатчан программалар бүлеге башлыгы И.Ш. Гафуровка һәм агросәнәгать комплексын инженерлык-техник яктан тәэмин итү бүлеге башлыгы Р.Н. Булатовка авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләрдән, крестьян (фермер) хуҗалыкларыннан, индивидуаль эшкуарлардан федераль бюджеттан һәм Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр алу өчен тапшырыла торган документларын кабул итүне тәэмин итәргә.

5. Финанс бүлеге башлыгы М.А. Мәхмүтовка авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә, крестьян (фермер) хуҗалыкларына, индивидуаль эшкуарларга субсидияләрне үз вакытында бирүне тәэмин итәргә.

6. “Ведомство максатчан программаларын һәм ведомство максатчан программаларын гамәлгә ашыруда катнашучы авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә субсидияләр бирү тәртипләрен раслау турында” Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының 2014 елның 27 февралендәге 40/2-пр номерлы боерыгын үз көчен югалткан дип танырга.

7. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны министрның беренче урынбасары Н.Л. Титовка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
урынбасары – министр М.Г. Әхмәтов

2015 елның 8 сентябрендәге 210-2/пр номерлы
ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы боерыгына
1 нче кушымта

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ ҺӘМ АЗЫК-ТӨЛЕК МИНИСТРЛЫГЫ**

# “2015 – 2017 елларга Татарстан Республикасында ит очен терлек үрчетүне үстерү”

## ведомство максатчан икътисадый әһәмиятле региональ программасы

**Казан 2015**

**Эчтәлек**

1. “2015 – 2017 елларга Татарстан Республикасында ит өчен терлек үрчетүне үстерү” ведомство максатчан икътисадый әһәмиятле региональ программасы паспорты ……………………………………………………………………..…..................3

2. Хәл ителеше программада карала торган проблемаларга характеристика. ………5

2.1. Ит өчен терлек үрчетүне үстерүдәге вәзгыятьне һәм аның мөмкинлекләрен анализлау ……………..........................................................................................7

2.2. Татарстан Республикасында ит өчен терлек үрчетүнең торышына анализ ………8

3. Төп максатлар һәм бурычлар ………………………………………………….............8

3.1. Максат индикаторлары………………………………………………….…….....9

3.2. Программа чараларының исемлеге һәм тасвирламасы ……………………….....10

3.3. Программаның соцциаль-икътисадый һәм экологик нәтиҗәлелеге ……….........10

3.4. Программа буенча бюджет акчаларын тотуның нәтиҗәлелегенә исәп-хисап …12

3.5. Программаның ресурс тәэминатын нигезләү ……………………......…………12

3.6. Программаны тормышка ашыруга идарә итү системасына тасвирлама ..……...14

3.7. Программа чараларын тормышка ашыру графигы ..……………………………15

3.8. Ит өчен терлек үрчетүне алып баруның заманча технологияләре буенча белгечләр әзерләүне оештыру һәм аларның квалификациясен күтәрү ……………16

4. “2015 – 2017 елларга Татарстан Республикасында ит өчен терлек үрчетүне үстерү” программасын тормышка ашыруның нәтиҗәлелеген тәэмин итү чаралары ……....16

**1.** “2015 – 2017 елларга Татарстан Республикасында ит өчен терлек үрчетүне үстерү” ведомство максатчан икътисадый әһәмиятле региональ программасы

**ПАСПОРТЫ**

| **Программаның исеме** | **“2015 – 2017 елларга Татарстан Республикасында ит өчен терлек үрчетүне үстерү”** |
|---|---|
| Программаны эшләү өчен нигез | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “2013 – 2020 елларга авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чималы һәм азык-төлек базарларын җайга салу буенча дәүләт программасы турында” 2012 елның 14 июлендәге 717 номерлы карары<br>Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “2013 – 2020 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чималы һәм азык-төлек базарларын җайга салу” дәүләт программасын раслау турында” 2013 елның 8 апрелендәге 235 номерлы карары |
| Программаның заказчысы | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы |
| Программаны төп эшләүчеләр | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы |
| Программаның максаты | Татарстан Республикасында ит өчен терлек үрчетүне булдыру һәм тотрыклы үстерү, сыер итен җитештерүнең конкуренциягә сәләтле булуын арттыру өчен икътисадый һәм технологик шартлар тудыру.<br>Югары сыйфатлы сыер итен җитештерү күләмен арттыру.<br>Ит өчен терлек үрчетү тармагын техник яктан яңадан җиһазлау.<br>Сыер итен куллану дәрәҗәсен арттыру |
| Төп бурычлар | Билгеләнгән максатка ирешү өчен түбәндәге бурычларны хәл итәргә кирәк:<br>- махсус ит токымнарыннан булган мөгезле эре терлекнең баш санын арттыру;<br>- ит өчен терлек үрчетүнең нәсел базасын ныгыту;<br>- ит җитештерүне арттыру һәм ит өчен терлек үрчетүне тизләтелгән үстерү;<br>- ит куллануны, аның һәркем алырлык булуын һәм халык өчен экологик куркынычсызлыгы дәрәҗәсен арттыру;<br>- авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләрнең заманча технологик җиһазлар, матди ресурслар белән тәэминатын яхшырту |
| Программада катнашучылар | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы;<br>“РАСХН Татарстан авыл хуҗалыгы фәнни-тикшеренү институты” дәүләт фәнни учреждениесе;<br>Ит өчен терлек үрчетү буенча Бөтенроссия фәнни-тикшеренү институты (ВНИИМС) Оренбург ш.; |

| | |
|---|---|
| | “Бауман исемендәге Казан дәүләт ветеринария медицинасы академиясе” федераль дәүләт югары һөнәри белем бюджет мәгариф учреждениесе;<br>Татарстан Республикасының авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр |
| Программаны тормышка ашыруның сроклары һәм баскычлары | Программа 2015-2017 елларда тормышка ашырыла<br>Ит бирә торган токымнардан югары сыйфатлы сыер итен җитештерүне шактый арттыру очен чаралар өч ел дәвамында гамәлгә ашырылачак. |
| Программаны үтәүчеләр | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы;<br>“РАСХН Татарстан авыл хуҗалыгы фәнни-тикшеренү институты” дәүләт фәнни учреждениесе;<br>Ит өчен терлек үрчетү буенча Бөтенроссия фәнни-тикшеренү институты (ВНИИМС) Оренбург ш.;<br>“Бауман исемендәге Казан дәүләт ветеринария медицинасы академиясе” федераль дәүләт югары һөнәри белем бюджет мәгариф учреждениесе;<br>Татарстан Республикасының авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләре. |
| Финанслау күләмнәре һәм чыганаклары | 2015-2018 елларда программаны тормышка ашыруга чыгымнарның гомуми күләме 1679,8 млн. сум тәшкил итәчәк, шул исәптән еллар буенча: 2015 – 522,6 млн. сум, 2016 – 559,9 млн. сум, 2017 – 597,3 млн. сум,<br>Татарстан Республикасы бюджеты исәбеннән – 353,2 млн. сум, шулардан еллар буенча:<br>2015 – 110,0 млн. сум, 2016 – 117,6 млн. сум, 2017 – 125,6 млн. сум,<br>бюджеттан тыш акчалар исәбеннән 1326,6 – млн. сум, шул исәптән еллар буенча:<br>2015 – 412,6 млн. сум, 2016 – 442,3 млн. сум, 2017 – 471,7 млн. сум |
| Максат индикаторы һәм программаның күрсәткечләре | Программаның күрсәткечләре:<br>ит бирә торган токымнардагы терлек санын 27,7 мең баштан (2014 елда) 41,2 мең башка кадәр арттыру, шул исәптән сыерларны 14,6 мең баштан 2017 елга 19,4 мең башка кадәр арттыру;<br>ит бирә торган терлектән югары сыйфатлы ит алуны тере авырлыктагы 2014 елдагы 2,9 мең тоннадан 2017 елда 5,1 мең тоннага кадәр арттыру |
| Программаны тормышка ашырудан көтелә торган | Ит бирә торган чиста токымлы һәм катнаш терлектән югары сыйфатлы сыер итен алуны тере авырлыктагы 2014 елдагы 2,9 мең тоннадан 2017 елда 5,1 мең тоннага кадәр арттыру.<br>ит бирә торган токымнардагы терлек санын 27,7 мең баштан |

| | |
|---|---|
| нәтиҗәләр | (2014 елда) 41,2 мең башка кадәр арттыру, шул исәптән сыерларны 14,6 мең баштан 2017 елга 19,4 мең башка кадәр арттыру;<br>халыкның эш белән тәэминатын арттыру, 123 өстәмә эш урыны булдыру. |
| Идарә итү һәм тикшереп тору системасы | Тулаем программаны тормышка ашыру өчен Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының терлекчелек тармакларын үстерү бүлеге җаваплы була. |

## 2. Хәл ителеше программада карала торган проблемаларга характеристика.

Татарстан Республикасының ит өчен терлек үрчетүне үстерүдәге кайбер тенденцияләрне уңай дип әйтеп булмый.

Авыл хуҗалыгы оешмаларында һәм халыкның шәхси ярдәмче хуҗалыкларында мөгезле эре терлекнең баш саны кимүгә таба үзгәрә, гәрчә терлекчелектәге төп күрсәткечләрнең уңай динамикасы сакланып калса да, ирешелгән аерым продуктивлык күрсәткечләренең дәрәҗәсе җитәрлек канәгатьләндерерлек түгел. Аерым алганда, 2010-2014 елларда барлык категория хуҗалыкларында ит җитештерү 165,8 мең тоннадан 153,9 мең тоннага кадәр кимеде.

Татарстан Республикасының авыл хуҗалыгын үстерүдәге тискәре факторларга түбәндәгеләр керә:

а) базар – авыл хуҗалыгы продукциясенә, шул исәптән иткә, сәнәгать продукциясенә һәм энергия чыганакларына бәяләр диспаритеты. Сәнәгать продукциясенә һәм энергия чыганакларына бәяләр белән авыл хуҗалыгы продукциясенә бәяләр арасында гомер гомергә аерманың зур булуы кимеп кенә калмый, хәтта артуга таба бара. Авыл хуҗалыгы продукциясенең төп төрләренә бәяләрнец аз гына үскәндә, җитештерү өчен кирәкле матди-техник ресурсларга һәм аеруча энергия чыганакларына бәяләрнең динамик артуы күзәтелә, бу нигездә табигый монополияләрнең хезмәт күрсәтүләренә бәяләр һәм тарифлар үзгәрү белән бәйле;

б) макроикътисадый – азык-төлекне импорттан кертү арту шартларында авыл хуҗалыгы продукциясе базарында конкуренция шартлары начарлану;

в) финанс-икътисадый – авыл хуҗалыгын үстерүгә һәм авылны социаль яктан төзекләндерүгә ярдәм итү өчен бирелә торган федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчалары күләменең җитәрлек булмавы;

г) идарә – Россия икътисадын һәм авыл хуҗалыгын үстерүнең региональ аспектларны һәм бюджет күрсәткечләре арасындагы үзара бәйләнешне исәпкә алган озак вакытка исәпләнгән стратегиянең булмавы.

Татарстан Республикасының ит өчен терлек үрчетүне үстерүдәге актуаль проблемаларга түбәндәгеләр керә:

а) структур – институциональ үзгәртеп коруларның акрын баруы, җитештерүне һәм беренчел эшкәртүне оештыру өлкәләрендә эшкуарлыкның кече формаларның, шулай ук авыл хуҗалыгы кулланучылары (эшкәртүче, сатучы (сату-

алучы), хезмәт күрсәтүче, тәэмин итүче һәм әзерләүче) кооперативларының начар үсүе;

б) базар – ит бәяләрендәге кискен үзгәрешләр; күпләп сату азык-төлек базарларының үсеш алмавы; конкуренцияне үстерүгә ярдәмнең житәрлек дәрәҗәдә булмавы; Татарстан Республикасының азык-төлек ягыннан куркынычсызлыгы принципларына таянган авыл хуҗалыгы продукциясен кертү-чыгару сәясәтендәге юнәлешләрнең төгәл билгеләнмәве;

в) финанс-икътисадый – авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләрнең финанс ягыннан тотрыксыз булуы, авыл хуҗалыгы оешмаларының инвестицияләрне җәлеп итүчәнлеге түбән булуы, кредит ресурсларын алу кыен булу һәм залог белән тәэминатның җитмәве, җир ресурсларын кадастр бәяләве һәм теркәве процессларының төгәлләнмәве аркасында ипотека кредитлары бирүнең үсеш алмавы; Татарстан Республикасы бюджетының авыл хуҗалыгын үстерүгә һәм авылны социаль төзекләндерүгә ярдәм итү өчен бирелә торган акчаларның күләме чикләнгән булу, шулай ук аларның нәтиҗәле сарыф ителмәве;

г) җитештерү – төп җитештерү фондларының, аларның яңаларын кертү белән чагыштырганда, кими баруы, технологик җиһазларның искерүе; заманча технологияләрнең түбән темплар белән кертелүе;

д) оештыру-идарә һәм кадрлар – идарә итү технологияләрен (бюджетлау нәтиҗәләре буенча идарә итү), мәгълүмат технологияләрен һәм инновацияләрне кертүнең җитәрлек булмавы, идарә итү өлкәсендәге оештыру ягыннан үзгәртеп коруларның озак вакытка сузылуы, квалификацияле идарәче һәм белгеч кадрлар кытлыгы, яшь белгечләрнең китүе;

е) социаль – авыл җирлекләрендәге яшәү шартларының кызыктырырлык булмавы, авыл халкының яшәү дәрәҗәсе югары булмау, социаль инфраструктура (сәламәтлек саклау, мәгариф, мәдәният) хезмәт күрсәтүләренең сыйфаты начар булу, тууның кимүе, яшьләрнең китүе.

Хәзерге вакытта Россиянең ит һәм ит продуктлары базарлары ресурсларының зур өлеше импорт хисабына формалашуын дәвам итә. Россия өчен азык-төлек куркынычсызлыгын хәл итү нигездә үзебезнең производствоны үстереп үз-үзебезне туклану продуктлары белән тәэмин итүгә кайтып кала. Азык-төлек куркынычсызлыгын хәл итүнең төп чарасы буларак һәрвакыт импортка йөз тоту ил икътисадына зыян китерә: ит импортын сатып алуга һәм аңа хезмәт күрсәтүгә сарыф ителгән миллиардлаган долларлар исә ул үзенең асылы белән ит җитештерүне үстерүгә тотылмаган инвестицияләрне тәшкил итә.

“2015 – 2017 елларга Татарстан Республикасында ит өчен терлек үрчетүне үстерү” программасы ит өчен терлек үрчетүне модернизацияләүгә юнәлтелгән. Югары сыйфатлы сыер итен җитештерүне арттыру илнең чит илдән кертелә торган иткә бәйлелекне өлешчә булса да киметергә мөмкинлек бирәчәк.

Программаны гамәлгә ашыру кысаларында ит бирә торган терлек токымнарының баш санын арттыру, аларны асрау һәм ашату технологияләренең камилләштерелүе хисабына аның продуктивлыгын күтәрү, культуралар үстерелә торган көтүлекләрне яхшырту күздә тотыла.

## 2.1 Ит өчен терлек үрчетүне үстерүдәге вәзгыятьне һәм аның мөмкинлекләрен анализлау

Республикада ит өчен терлек үрчетү тармагын үстерү буенча максатчан эшләр алып барыла, ул җирле арзан азыкны кулланып югары сыйфатлы сыер итен җитештерергә мөмкинлек бирәчәк.

Ит өчен терлек үрчетү – биналар төзүгә һәм механикалаштыру чараларына күләмле булмаган чыгымнар таләп итә торган, югары хезмәт җитештерүчәнлегенә ирешергә мөмкинлек бирә торган тармак. Ит бирә торган терлек көтүлекләрдән, кыр эшләреннән һәм, концентратлар күп кулланылмаган очракларда, эшкәртү сәнәгатеннән калган продукцияне нәтиҗәле файдалана ала. Шулай булса да ит бирә торган терлек яхшы азык, бай туклану белән тәэмин ителгән булырга тиеш. Бу системаны, беренче чиратта, азыкка зур чыгымнар тотыла торган аз продуктив савым сыерлары булган, сөт җитештерү файдалы булмаган хуҗалыкларга керттеләр.

Ит өчен терлек үрчетүне үстерү чагыштырмача аз капитал салулар һәм аз хезмәт чыгымнары белән югары сыйфатлы сыер итен җитештерүне арттыру проблемасын хәл итәргә мөмкинлек бирә.

Үзгәргән икътисадый вәзгыять һәм базар икътисадына күчү беренче чиратта, алдагысыннан аермалы буларак, энергия һәм хезмәтне азрак таләп иткән ит өчен терлек үрчетүне үстерүгә нигез бирә. Ит өчен терлек үрчетү технологиясен ресурсларны сак тота торган технологияләргә кертеп карарга була.

Республикада ит бирә торган чиста мөгезле эре терлек токымнарын үрчетүдә махсуслашкан хуҗалыкларның саны 2006 елдан башлап 3 тән 23 кә кадәр арткан.

Ит өчен терлек үрчетү республикада ике юнәлештә алып барыла.

**Беренче юнәлеш** – ит өчен махсуслашкан көтүләр булдыру.

Бүгенге көнгә 4 нәселле репродуктор булдырылды: гереформ токымы буенча Кама Тамагы районының “Кама Тамагы” ҖЧҖ, обрак токымы буенча Актаныш районының «Чиялек» ҖЧҖ, абердин-ангус токымы буенча Арча районының “ПХ Пионер” ҖЧҖ һәм лимузин токымы буенча Саба районының «Мартен» ҖЧҖ. Әлеге хуҗалыклар республиканың ит бирә торган терлек үрчетү белән шөгыльләнә торган товар хуҗалыкларына сатыла торган үгезләр үстерү белән шөгыльләнәләр.

**Икенче юнәлеш** сөт бирә торган сыерларны ит бирә торган токымлы үгезләр белән сәнәгать шартларында кушуны куллануда гыйбарәт. Бу юнәлеш республикада киңрәк таралган, чөнки бу максатларда аз продуктив сыерларның 30 процентына кадәрен һәр хуҗалыкта кулланырга була. Алга таба катнаш башларның саны арта бару белән йота бара торган кушуны куллану максатка ярашлы була. Беренче буын үгезләрен һәм начаррак таналарны иткә җибәрәләр, ә иң яхшы таналарны көтүгә кушалар. Алар акрын-акрын беренче вакытларда ит көтүләрен тәшкил иткән сөт бирә торган сыерларны алыштыра баралар. Төп көтүгә кушу өчен калдырылган таналарны ит токымын яхшырта торган шундый ук токымлы үгезләр белән каплаттыралар.

Сөт сыерыннан туган бозаулар бары тик ит алу өчен генә кулланыла торган шәхси сектордагы терлекчелектә сәнәгать шартларында кушуны кертү шулай ук өметле. Крестьян (фермер) хуҗалыкларында сыерлар 7-8 яшькә кадәр бозау

китерәләр, шуңа күрә беренче 3 – 4 бозауны ит токымы үгезләреннән тудыру, ә калган бозауларны алмаш таналар үстерү өчен сөт үгезләреннән тудыру файдалы була.

## 2.2. Татарстан Республикасында ит өчен терлек үрчетүнең торышына анализ

| № т/б | Күрсәткечләр | Санау берәмлеге | 2010 ел | 2011 ел | 2012 ел | 2013 ел | 2014 ел | 2010 елга карата 2014 елда, % |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Ел ахырына мөгезле эре терлекнең баш исәбе (хуҗалыкларның барлык категорияләрендә) | мең баш | 1124,5 | 1092,4 | 1073,4 | 1029,9 | 1030,2 | 92 |
| 2 | Ит бирә торган терлекнең баш саны (хуҗалыкларның барлык категорияләрендә) | баш | 31451 | 34389 | 34800 | 26807 | 32653 | 104 |
| 2.1 | шул исәптән ана башлар | баш | 15538 | 13133 | 17048 | 14141 | 15580 | 100 |
| 3 | Мөгезле эре терлек итенең тере авырлыгында иткә җибәрү өчен җитештерү (хуҗалыкларның барлык категорияләрендә) | мең тонна | 165,8 | 158,9 | 158,6 | 158,2 | 153,9 | 93 |
| 4 | Ит бирә торган һәм катнаш терлек итенең тере авырлыгында иткә җибәрү өчен җитештерү (хуҗалыкларның барлык категорияләрендә) | тонна | 3508 | 3666 | 4609 | 4100 | 3250 | 93 |
| 5 | Халыкның җан башына сыер итен җитештерү | кг | 43,8 | 41,9 | 41,7 | 41,4 | 40,1 | 92 |
| 6 | Ит җитештерүнең рентабельлеге дәүләт ярдәме белән | % | -21,6 | -21,4 | -16,6 | -24,1 | -24,2 | - |
| 6.1 | дәүләт ярдәменнән башка | % | -38,1 | -34,8 | -31,2 | -34,6 | -29,7 | - |

Татарстан Республикасында ит өчен терлек үрчетүне үстерү өчен уңай табигый һәм икътисадый шартлар бар. Республикада мөгезле эре терлекнең баш саны шактый зур. Моның өчен тотрыклы азык базасы булдырылган. Икмәк һзм эшкәртү сәнәгате калдыклары күп. Табигый көтүлекләр һәм печәнлекләр арзан азык чыганагы булып торалар, аларның мәйданы 1010 мең гектар яки барлык авыл хуҗалыгы кырларының 22 процентын тәшкил итә.

## 3. Төп максатлар һәм бурычлар

Программаның максаты – Татарстан Республикасында ит өчен терлек үрчетүне булдыру һәм аны тотрыклы үстерү һәм сыер итен җитештерүнең конкуренциягә сәләтлелеген арттыру өчен икътисадый һәм технологик шартлар тудыру.

Максатка ирешү өчен түбәндәге бурычларны хәл итәргә кирәк:

2013 – 2020 елларга авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чималы һәм азык-төлек базарларын җайга салу буенча дәүләт программасын тормышка ашыру кысаларында югары сыйфатлы сыер итен җитештерүне арттыру һәм ит өчен терлек үрчетүне тизләтелгән үстерү.

авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләрне заманча технологик җиһазлар һәм матди ресурслар; квалификацияле кадрлар белән тәэмин итүне яхшырту.

Татарстан Республикасы халкын җирле сыйфатлы авыл хуҗалыгы продукңиясе белән тәэмин итү, ит куллану дәрәҗәсен күтәрү, аның һәркем алырлык булуы һәм халык өчен экологик куркынычсыз булуы.

республикага кертелә торган продукцияне алыштыру һәм Татарстан Республикасында җитештерелгән авыл хуҗалыгы продукциясен экспортка чыгару.

### 3.1. Максат индикаторлары
### “2015 – 2017 елларга Татарстан Республикасында ит өчен терлек үрчетүне үстерү” программасының төп максат индикаторлары һәм аларның күрсәткечләре

| № т/б | Күрсәткечләр | Исәпләү берәмлеге | 2014 факт | 2015 | 2016 | 2017 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Авыл хуҗалыгы предприятиеләрендә ит бирә торган махсус терлекнең һәм катнаш терлекнең баш саны | мең баш | 27,7 | 35,5 | 38,3 | 41,2 |
| 1.2 | Шул исәптән сыерлар | мең баш | 14,6 | 16,4 | 17,8 | 19,4 |
| 2 | Авыл хуҗалыгы предприятиеләрендә ит бирә торган махсус терлекнең баш саны | мең баш | 4,2 | 4,7 | 5,2 | 6,4 |
| 2.1 | Шул исәптән сыерлар | мең баш | 1,8 | 2,1 | 2,4 | 2,7 |
| 3 | Авыл хуҗалыгы предприятиеләрендә ит бирә торган катнаш терлекнең баш саны | мең баш | 23,5 | 30,8 | 33,1 | 34,8 |
| 3.1 | Шул исәптән сыерлар | мең баш | 12,8 | 14,3 | 15,4 | 16,7 |
| 4 | Авыл хуҗалыгы предприятиеләрендә ит бирә торган терлекне һәм алар белән катнаштырылган терлекне тер авырлыгында иткә җибәрү өчен җитештерү | мең баш | 2,9 | 4,0 | 4,5 | 5,1 |
| 5 | Программаны гамәлгә ашыру кысаларында ит өчен терлек үстерү белән шөгыльләнүче халык саны | кеше | 365 | 395 | 438 | 488 |

## 3.2. Программа чараларының исемлеге һәм тасвирламасы

Программаның төп бурычларын хәл итү һәм максатларга ирешү өчен түбәндәге юнәлешләр буенча үзара бәйләнгән һәм килештереп башкарыла торган чаралар комплексын гамәлгә ашырырга кирәк:

1. Ит өчен терлек үстерү тармагын яңадан техник, технологик җиһазлау һәм комплекслы модернизацияләү өчен шартлар тудыру.

Әлеге юнәлешне гамәлгә ашыруга дәүләт ярдәме ит бирә торган токымнарга караган мөгезле эре терлекне үрчетү буенча фермаларны һәм фидлотларны (ачык симертү мәйданнарын) төзү, реконструкцияләү, модернизацияләү, электр тапшыргыч линияләр үткәрү, су белән тәэмин итү линияләре һәм аларга бару юлларын салу, шулай ук технологик җиһаз һәм азык хәзерләү техникасын сатып алу чыгымнарының бер өлешен компенсацияләү юлы белән башкарыла.

2. Сыер итен җитештерү чыгымнарын киметүнең икътисадый шартларын тудыру, ит өчен терлек үрчетү белән шөгыльләнүче авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләрнең финанс тотрыклылыгына ирешү.

Әлеге юнәлешкә дәүләт ярдәме шулай ук авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә товарлык көтүләрдә сыерны бозавы белән бергә асрауга субсидияләр (товарлык көтүләрдәге ит бирә торган бер сыерга исәпләүдән чыгып) бирү юлы белән күрсәтеләчәк.

3. Югары сыйфатлы сыер итен җитештерүне арттыру.

Әлеге юнәлешкә дәүләт ярдәме республиканың авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләренә 2 яшьтән зуррак булмаган кимендә 450 кг лы тере авырлыктагы чиста токымлы һәм катнаш яшь мөгезле эре терлек итен сату чыгымнарының бер өлешен компенсацияләү юлы белән башкарылачак.

## 3.3. Программаның социаль-икътисадый һәм экологик нәтиҗәлелеге

Программаны тормышка ашыру ит терлеген үрчетү һәм симертү белән шөгыльләнә торган предприятиеләрнең тизрәк үсүе өчен терлекне тере авырлыгы 450 кг кадәр һәм аннан да күбрәккә симертүне стимуллаштырып, ит җитештерә һәм симертә торган предприятиеләр булдырып һәм технологик модернизацияләп, техника паркларын яңартып шартлар тудырачак.

Махсуслаштырылган ит терлеге булган терлекчелек предприятиеләрен үстерүгә юнәлтелгән инвестиция проектларын тормышка ашыру 1313 млн. сум тирәсендә инвестицияләр җәлеп итәргә мөмкинлек бирәчәк, аның хисабына терлекчелек комплекслары һәм фермаларына реконструкция һәм модернизация башкарылачак. Ит терлегенең баш исәбе 27,2 мең баштан 41,2 мең башка кадәр яки 51 процентка артачак, нәселле ана башларның саны 69 процентка артачак һәм 2,7 мең баш тәшкил итәчәк.

Республикада хайваннарның ит өчен продуктивлыгы товар көтүнең генетик потенциалы арту хисабына ел саен 5 процентка артып барачак. 2016 елда ит терлегеннән 5,1 мең тонна югары сыйфатлы сыер ите җитештереләчәк. Ит үгезләренең биопродукциясен куллану яхшы икътисадый нәтиҗә бирәчәк. Ит өчен

терлек үрчетүгә ярдәм итү махсуслаштырылган предприятиеләрдә яшь терлекне тере массасы 450 килограммга кадәр һәм аннан да күбрәк симертергә мөмкинлек бирәчәк, бу исә югары сыйфатлы сыер итен җитештерү проблемасын хәл итәргә мөмкинлек бирәчәк, терлекне сәнәгать юлы белән катнаш кушылдыруны стимуллаштырачак.

Азык җыя торган авыл хуҗалыгы техникасын, азык хәзерләү өчен машиналар һәм җиһазлар комплексын сатып алып матди-техник базаны ныгыту предприятиеләрне сыйфатлы азык белән җитәрлек дәрәҗәдә тәэмин итәргә, ит өчен терлек үрчетүнең җитештерү һәм технологик платформаларын ныгытырга һәм яңартырга мөмкинлек бирәчәк. Тулаем алганда, ит терлегеннән сыер итен җитештерүнең файдасы артачак һәм 8,1 процenттан алып 16,5 процентка кадәр тәшкил итәчәк.

Программаны тормышка ашыру, югары сыйфатлы сыер итен җитештерүне арттырудан һәм әлеге төр ит белән эчке базарны тутырудан тыш, Татарстан Республикасының авыл җире территорияләрендә яңа эш урыннары булдыруны тәэмин итәчәк.

**Программаның социаль-икътисадый нәтиҗәлелегенә анализ**

| № т/б | Күрсәткечләр | Исәплəү берәмлеге | 2014 факт | 2015 | 2016 | 2017 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Авыл хуҗалыгы предприятиеләрендә ит бирә торган терлекнең һәм катнаш терлекнең баш саны | мең баш | 27,7 | 35,5 | 38,3 | 41,2 |
| 1.2 | Ит бирә торган терлекнең ана башлары | мең баш | 14,6 | 16,4 | 17,8 | 19,4 |
| 2 | Авыл хуҗалыгы предприятиеләрендә тере авырлыкта иткә җибәрү өчен сыер ите җитештерү | мең тонна | 78,7 | 81,1 | 83,5 | 86,0 |
| | | % | 94 | 103 | 103 | 103 |
| 3 | Авыл хуҗалыгы предприятиеләрендә ит бирә торган терлекне һәм алар белән катнаштырылган терлекне тере авырлыгында иткә җибәрү өчен җитештерү | мең тонна | 2,9 | 4,0 | 4,5 | 5,1 |
| | | % | 83 | 138 | 113 | 113 |
| 4 | Сатканда бер баш терлекнең уртача тере массасы | кг | 500 | 500 | 500 | 500 |
| 5 | Ит бирә торган махсус терлекнең 1 башын арттыруга чыгымнар | мең сум | 24,0 | 26,0 | 29,0 | 30,0 |
| 6 | Ит белән шөгыльләнә торган халыкның саны арту | кеше | 25 | 30 | 43 | 50 |

Программаның максат индикаторлары һәм аларның икътисадый нәтиҗәлелеге индикаторлары динамикасына анализ нәселле терлекнең исәбен шактый арттыруның һәм югары сыйфатлы сыер итен җитештерү күләмнәрен һәм ит терлегенең гомуми баш исәбен арттыруның мөмкин булуын күрсәтә.

## 3.4. Программа буенча бюджет акчаларын тотуның нәтиҗәлелегенә исәп-хисап

| Күрсәткечләр | | Исәпләү берәмлеге | 2015 ел | 2016 ел | 2011 ел | 3 елга барлыгы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Сыер итен сатудан алынган табыш (ТП) | | **млн. сум** | **8180,0** | **8756,0** | **9366,0** | **26302,0** |
| Сыер итен сатудан алынган табышның еллык артымы (ΔТП) | | **млн. сум** | **540,0** | **576,0** | **610,0** | **1726,0** |
| Программаны финанслау | барлыгы (Ф) | 523,0 | 560,0 | 597,0 | 1680,0 | 850 |
| Нәтиҗәлелек күрсәткечләре | $Э_{общ.}$ | 103 | 103 | 102 | 103 | 6,8 |
| Табыш артымы | | % | 104 | 107 | 107 | 109 |

Финанслау акчаларын тоту нәтиҗәлелеге программаның ахыргы нәтиҗәләренең һәм чыгымнарның аны $Э_{общ}$ коэффициенты буенча тормышка ашыруга нисбәте буенча билгеләнә, ул төп индикаторның (бәягә салынган тулаем продуктның) финанслауның гомуми күләменә нисбәтен түбәндәге формула буенча күрсәтә:

$Э_{общ} = ΔТП/Ф \times 100$ проңент,

монда:
$Э_{общ}$ – финанс чараларын тотуның гомуми нәтиҗәлелеге коэффициенты;
ΔТП – ит товар продукциясенең бәягә салынган еллык артымы,
Ф – продукцияне җитештерүне финанслау күләме.

## 3.5. Программаның ресурс тәэминатын нигезләү

Программаны финанслау республика бюджеты акчалары исәбеннән һәм бюджеттан тыш чыганаклардан акчалар җәлеп итеп башкарылачак.

Программаның планлаштырылган чараларын тормышка ашыруга кирәк булган акчаларның күләме түбәндәгеләрне исәпкә алып исәпләнә:

2014 елда нәселле терлеккә импорт буенча һәм ил эчендәге фактик бәяләрне;

республика буенча уртача ит сыерларын асрау чыгымнарын;

ит җитештерүнең республика буенча уртача производство чыгымнарын.

Программаның барлык чараларын финанслау күләмнәре һәм чыганаклары буенча исәп-хисаплар һәм башлангыч саннар таблицада китерелгән.

**Программа чараларын финанслауга гомуми ихтыяҗ һәм аның чыганаклары, млн. сум.**

| № т/б | Чаралар | Чыганак | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2016-2014 елларда барлыгы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Ит бирә торган токымнарга караган мөгезле эре терлекне үрчетү буенча фермаларны һәм фидлотларны (ачык симертү мәйданнарын) төзү, реконструкцияләү, модернизацияләү, электр тапшыргыч линияләр үткәрү, су белән тәэмин итү линияләре һәм аларга бару юлларын салу, шулай ук технологик җиһаз һәм азык хәзерләү техникасын сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидияләр | Региональ бюджет | 86,0 | 92,0 | 98,0 | 276,0 |
| | | Бюджеттан тыш акчалар | 323,0 | 346,0 | 368,0 | 1037,0 |
| 2 | Товарлык көтүләрдә сыерны бозавы белән бергә асрауга субсидияләр (товарлык көтүләрдәге ит бирә торган бер сыерга исәпләүдән чыгып) | Региональ бюджет | 10,0 | 10,5 | 11,3 | 31,8 |
| | | Бюджеттан тыш акчалар | 37,0 | 39,5 | 42,4 | 118,9 |
| 3 | 2 яшьтән зуррак булмаган кимендә 450 кг лы тере авырлыктагы чиста токымлы һәм катнаш яшь мөгезле эре терлек итен сатуга субсидияләр | Региональ бюджет | 14,0 | 15,1 | 16,3 | 45,4 |
| | | Бюджеттан тыш акчалар | 52,6 | 56,8 | 61,3 | 170,7 |
| | **Барлыгы:** | Региональ бюджет | 110,0 | 117,6 | 125,6 | 353,2 |
| | | Бюджеттан тыш акчалар | 412,6 | 442,3 | 471,7 | 1326,6 |
| | | **БАРЫСЫ** | **522,6** | **559,9** | **597,3** | **1679,8** |

**Татарстан Республикасында 2015 –2017 елларда симертү мәйданнарын һәм азык бирү урыннарын төзүче хуҗалыкларның исемлеге**

| № т/б | Муниципаль районның исеме | Хуҗалык исеме |
|---|---|---|
| 1 | Әгерҗе | «Нәүрүз» ҖЧҖ |
| 2 | Азнакай | «АгроТНГС-И» ҖЧҖ |
| 3 | | «Агрофирма "Азнакай» ҖЧҖ |
| 4 | Актаныш | «Чиялек» ҖЧҖ |
| 5 | | «Агрофирма «Әнәк» ҖЧҖ |
| 6 | Әлки | «Хузангай» СХПК |
| 7 | Әлмәт | «Н.Е. Токарликов исемендәге» ААҖ |
| 8 | Апас | «Свияга» СХПК |
| 9 | Арча | «Агрокомплекс «Ак Барс» ҖЧҖ |
| 10 | Балтач | «Яңа тормыш» ҖЧҖ |
| 11 | | «Тимерязев исемендәге» ҖЧҖ |
| 12 | | «Смаиль» ҖЧҖ СП |
| 13 | Бөгелмә | «Бөгелмә азык-төлек корпорациясе» ҖЧҖ |
| 14 | Югары Ослан | «Идел аръягы» ҖЧҖ АПК |
| 15 | Чүпрәле | «Ак Барс «Чүпрәле» ҖЧҖ |
| 16 | Алабуга | «АФ "Вятские Зори» ҖЧҖ |
| 17 | | «Светлая долина» ҖЧҖ |
| 18 | Зәй | «Агрофирма «Зәй» ҖЧҖ |
| 19 | Кама Тамагы | «Кама Тамагы» ҖЧҖ |
| 20 | Лаеш | Сарапкин О.Н. КФХ |
| 21 | Лениногорск | «Агрофирма «Лениногорск» ҖЧҖ |
| 22 | Мамадыш | «Азык-төлек программасы» ҖЧҖ АПК |
| 23 | Мөслим | «Родные края - Туган як» ҖЧҖ |
| 24 | | «Органик Групп» ҖЧҖ |
| 25 | Нурлат | Сулейманов А.И. КФХ |
| 26 | Балык Бистәсе | «Русский мрамор» ЯАҖ АПК |
| 27 | | Агрофирма «Солтан» ҖЧҖ |
| 28 | Саба | «Агрофирма «Мартен» ҖЧҖ |
| 29 | | «Нырты» ҖЧҖ СХП |
| 30 | Тәтеш | «Загидуллина Р.М.» КФХ |
| 31 | Тукай | «Агрофирма «Кама» ҖЧҖ |

### 3.6. Программаны тормышка ашыруга идарә итү системасына тасвирлама

Программаны тормышка ашыруга идарә итү системасы түбәндәгеләр буенча җаваплыларны раслауны күз алдында тота:

тулаем алганда Программаны тормышка ашыру, программа максатларына, бурычларына, максат индикаторларына ирешү, Программада расланган бурычлар һәм гамәлләр күрсәткечләре;

Программаны тормышка ашыруда катнаша торган учреждениеләр һәм оешмалар эшчәнлеген координацияләү һәм аларның программа чараларын тормышка ашыру буенча гамәлләрен килештерү;

Программаның һәр чарасын һәм, шуннан чыгып, программаны тормышка ашыру;

Программа гамәлләрне финанслау;

Программаның тормышка ашырылуын мониторинглау;

Программаны тормышка ашыру барышы турында хисап төзү.

## 3.7. Программа чараларын тормышка ашыру графигы

| № т/б | Программаның бүлекләре, чаралар | Эш күләме | Исәпләү берәмлеге | Үтәлеше өчен җаваплылар | Үтәү срогы |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Ит бирә торган токымлы мөгезле эре терлекнең баш исәбен арттыру | 14 | мең баш | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы; | 2015-2017 еллар |
| 2 | Азык базасын ныгыту һәм азыкның сыйфатын яхшырту | 24,5 | мең га | “РАСХН Татарстан авыл хуҗалыгы фәнни-тикшеренү институты” дәүләт фәнни учреждениесе” ДФУ | 2015-2017 еллар |
| 3 | Ит җитештерүне ел сезоннары буенча тигезләү һәм тотрыклы хәзерләү бәяләренә ирешү максатларында ит базарын җайга салу | 23-24 | мең тонна | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы; | 2015-2017 еллар |
| 4 | Татарстан агробизнес кадрларын яңадан әзерләү институтында эшләүче белгечләрнең квалификациясен күтәрү, ит токымнарына керә торган терлекне үрчетү буенча илнең алдынгы нәселле терлек хуҗалыкларында стажировка уздыру | 50 | кеше | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы | 2015-2017 еллар |

### 3.8. Ит өчен терлек үрчетүне алып баруның заманча технологияләре буенча белгечләр әзерләүне оештыру һәм аларның квалификациясен күтәрү

| Чаралар | Тормышка ашыру сроклары | Белгечләр саны |
|---|---|---|
| 1. Казан дәүләт ветеринария медицинасы академиясенең зооинженерлык факультетында студентларны сыер итен сәнәгатьтә житештерү белгечләре белән бергә әзерләүне оештыру. | 2015-2017 еллар | 30 |
| 2. Татарстан агробизнес кадрларын яңадан әзерләү институтында эшләүче белгечләрнең квалификациясен күтәрү, ит токымнарына керә торган терлекне үрчетү буенча илнең алдынгы нәселле терлек хуҗалыкларында стажировка уздыру | 2015-2017 еллар | 70 |
| 3. Хезмәт күрсәтүче персоналның производствода укуын турыдан туры хуҗалыкларда оештыру. | 2015-2017 еллар | 60 |

## 4. “2015 – 2017 елларга Татарстан Республикасында ит өчен терлек үрчетүне үстерү” программасын тормышка ашыруның нәтиҗәлелеген тәэмин итү чаралары

Татарстан Республикасында, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының таләпләренә туры китереп, барлык 43 муниципаль районны, шулай ук “2015 – 2017 елларга Татарстан Республикасында ит өчен терлек үрчетүне үстерү” программасы колачлаган районнарны территориаль планлаштыру схемалары һәм авыл җирлекләренең генераль планнары эшләнгән, алар муниципаль берәмлекләренең рәсми сайтларында бар.

2015 – 2017 елларга Татарстан Республикасында ит өчен терлек үрчетүне үстерү” программасы Татарстан Республикасының барлык 43 муниципаль районында хуҗалык итүнең кече, урта һәм эре формаларының, кулланучылар кооперацияләренең үзара бәйләнешын тәэмин итә.

Татарстан Республикасында “2014-2017 елларга һәм 2020 елга кадәрге чорга авыл территорияләрен тотрыклы үстерү” федераль максатчан программасы нигезендә “2014 – 2017 елларга һәм 2020 елга кадәрге чорга Татарстан Республикасының авыл территорияләрен тотрыклы үстерү” программасы эшләнде, анда “2015 – 2017 елларга Татарстан Республикасында ит өчен терлек үрчетүне үстерү” программасы тормышка ашыру урыннарында социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктураларын үстерү планнары исәпкә алына.

Бюджет чыгымнарының нәтиҗәлелеген арттыру максатларында муниципаль районнарда, заманча мәгариф үзәкләрен (база мәктәпләр) төзеп һәм кирәкле мәктәп автобуслары паркын тәэмин итеп, аз комплектлы мәктәпләрнең саны киметелде, республика ел саен мәктәпкәчә балалар учреждениеләрен, гомуми практика

табиблары офисларын һәм авылда заманча фельдшер-акушерлык пунктларын, спорт корылмаларын төзүне һәм реконструкцияләүне финанслый.

Федераль һәм республика бюджетларыннан “2015 – 2017 елларга Татарстан Республикасында ит очен терлек үрчетүне үстерү” программасын үтәү өчен авыл җирлегендә яшәүчеләрнең, шул исәптән яшь белгечләрнең тормыш шартларын яхшыртуга ел саен акчалар бүлеп бирү каралган. Моннан тыш, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды авыл җирендә торак төзүгә еллык 7 процентлы ипотека кредитлары бирә. “2015 – 2017 елларга Татарстан Республикасында ит өчен терлек үрчетүне үстерү” программасын үтәү өчен торак мәйданы 4,5 мең квадрат метр тәшкил иткән 45 йорт төзү каралган.

Татарстан Республикасында авыл инфраструктурасын һәм торак төзелешен үстерүгә “2014-2017 елларга һәм 2020 елга кадәрге чорга авыл территорияләрен тотрыклы үстерү” федераль максатчан программасына өстәп ел саен тагын кимендә 7 млрд. сум бүлеп бирү планлаштырыла.

Татарстан Республикасында Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджетка караганда артыграк финанслана торган заманча авыл инфраструктурасын булдыру буенча амбициоз планнар тормышка ашырыла.

2015 елның 8 сентябрендәге
210-2/пр номерлы
ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-
төлек министрлыгы боерыгына
2 нче кушымта

“2015 – 2017 елларга Татарстан Республикасында ит өчен терлек үрчетүне үстерү” ведомство максатчан икътисадый әһәмиятле региональ программасын гамәлгә ашыруда катнашучы авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә, крестьян (фермер) хуҗалыкларына, индивидуаль эшкуарларга 2015 елда субсидияләр бирү тәртибе

1. Әлеге Тәртип “2015 – 2017 елларга Татарстан Республикасында ит өчен терлек үрчетүне үстерү” ведомство максатчан икътисадый әһәмиятле региональ программасын (алга таба – Программа) гамәлгә ашыруда катнашучы авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә (алга таба – Программада катнашучылар) 2015 елда субсидияләр бирү механизмын билгели.

2. Субсидияләр әлеге Тәртипнең 1 пунктында каралган максатларга Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы (алга таба – Министрлык) раслаган бюджет йөкләмәләре чигендә бирелә.

3. Субсидияләр бирү шарты булып Программада катнашучыларның милкендә һәм (яки) аренда шартларында ит бирә торган махсус һәм катнаш мөгезле эре терлекнең (алга таба – ит бирә торган токымнарга караган мөгезле эре терлек) баш саны булу тора.

Субсидияләр бетү стадиясенә күчкән яки бөлгенлекка (банкротлыкка) чыккан дип танылган Программада катнашучыларга бирелми.

4. Субсидияләр бирү максатлары түбәндәгеләр:

ит бирә торган токымнарга караган мөгезле эре терлекнең баш санының 2015 елның 31 декабренә артуын тәэмин итә торган икътисадый һәм технологик шартлар тудыру;

ит җитештерү күләмнәрен арттыру.

5. Субсидияләр бирү өчен Программада катнашучыларны сайлап алу критериясе ит бирә торган токымнарга караган мөгезле эре терлекне үрчетүдән гыйбарәт.

6. Программада катнашучыларга субсидияләр түбәндәгечә бирелә:

а) ит бирә торган токымнарга караган мөгезле эре терлекне үрчетү буенча фермаларны һәм фидлотларны (ачык симертү мәйданнарын) төзү, реконструкцияләү, модернизацияләү, электр тапшыргыч линияләр үткәрү, су белән тәэмин итү линияләре һәм аларга бару юлларын салу чыгымнарының бер өлешен каплауга – Программа гамәлгә ашырыла башлаганчы бер ел эчендә башкарылган эшләр күләменең 75 проценты исәбеннән, шул исәптән федераль бюджет акчалары хисабына – 20 проценты;

б) технологик җиһаз һәм азык хәзерләү техникасын сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплауга Программа гамәлгә ашырыла башлаганчы бер ел эчендә сатып

алынган җиһаз һәм азык хәзерләү техникасы бәясенең 75 проценты исәбеннән, шул исәптән федераль бюджет акчалары хисабына – 20 проценты.

7. Әлеге Тәртипнең 6 пунктындагы а пунктчасында күрсәтелгән субсидияләрне алу өчен Программада катнашучылар Министрлыкка түбәндәге документларны тапшыралар:

түләү реквизитларын һәм почта адресын күрсәтеп, субсидияләр бирү соралган гаризаны;

субсидия бирү турында мөрәҗәгать иткән айның 1 нче числосына милкендә һәм (яки) аренда шартларында ит бирә торган токымнарга караган мөгезле эре терлекнең баш саны булу турында Министрлык раслаган форма буенча белешмәне;

төзүгә, реконструкцияләүгә һәм модернизацияләүгә җыелма исәп-хисап сметасының күчермәсен;

төзүгә, реконструкцияләүгә һәм модернизацияләүгә подряд шартнамәсенең күчермәсен;

"Башкарылган эшләрне кабул итү турында акт" КС-2 номерлы статистика формасы буенча белешмәне;

"Башкарылган эшләрнең һәм чыгымнарның бәясе турында белешмә" КС-3 номерлы статистика формасы буенча белешмәне;

эшләрне хуҗалык эшләре ысулы белән башкарганда "Башкарылган эшләрне кабул итү турында акт" КС-2 номерлы статистика формасы һәм "Башкарылган эшләрнең һәм чыгымнарның бәясе турында белешмә" КС-3 номерлы статистика формасы буенча белешмәләрне;

башкарылган эшләр өчен түләүне раслый торган банк тарафыннан таныкланган түләү йөкләмәсен;

Министрлык тарафыннан расланган форма буенча субсидияләр бирү өчен исәп-хисап белешмәләрен.

Тапшырыла торган документларның күчермәләре Программада катнашучылар тарафыннан таныклана.

8. Әлеге Тәртипнең 6 пунктындагы б пунктчасында күрсәтелгән субсидияләрне алу өчен Программада катнашучылар Министрлыкка түбәндәге документларны тапшыралар:

түләү реквизитларын һәм почта адресын күрсәтеп, субсидияләр бирү соралган гаризаны;

субсидия бирү турында мөрәҗәгать иткән айның 1 нче числосына милкендә һәм (яки) аренда шартларында ит бирә торган токымнарга караган мөгезле эре терлекнең баш саны булу турында Министрлык раслаган форма буенча белешмәне;

технологик җиһазны яки азык хәзерләү техникасын китерү (сату-алу) шартнамәсенең, товар накладноеның, ОС-1 формасы буенча кабул итеп алу-тапшыру актының күчермәсен;

технологик җиһаз яки азык хәзерләү техникасы өчен түләүне раслый торган банк тарафыннан таныкланган түләү йөкләмәсен;

җиһаз яисә техника паспортының (эшләнмә паспортының) күчермәсен;

Министрлык тарафыннан расланган форма буенча субсидияләр бирү өчен исәп-хисап белешмәләрен.

Тапшырыла торган документларның күчермәләре Программада катнашучылар тарафыннан таныклана.

9. Министрлык:

субсидияләр бирү соралган гаризаны кергән көнендә үк журналга терки, ул номерлана, шнурлана һәм аңа Министрлык мөһере сугыла;

гариза теркәлгән көннән алып 20 көн эчендә әлеге Тәртипнең 7 һәм 8 пунктлары нигезендә тапшырылган документларны карый һәм субсидия бирү турында яки субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.

Субсидия бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

Документларның тулы булмаган комплекты тапшырылу яки аларның әлеге Тәртип таләпләренә туры килмәве;

бюджет йөкләмәләре лимитлары калмау.

10. Министрлык Программада катнашучылар белән Министрлык тарафыннан расланган форма буенча Субсидия бирү турында килешү төзи.

11. Министрлык бюджет акчаларын баш бүлүче булып тора һәм акчаларны, Министрлык тарафыннан расланган субсидияләр бирү өчен җыелма исәп-хисап белешмәләренә нигезләнеп, үзенең Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсендә яки Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаментында ачылган хосусый счетыннан Программада катнашучыларның исәп-хисап счетларына әлеге Тәртипнең 9 пунктындагы икенче абзацында күрсәтелгән срок беткәннән соң биш көн эчендә күчерә.

12. Алынган субсидияләр, аларны бирүнең әлеге Тәртиптә билгеләнгән максатлары һәм шартлары бозылу, субсидияләрнең максатчан билгеләнеше буенча файдаланылмавы һәм (яки) дөрес булмаган белешмәләр һәм документлар тапшырылу очраклары билгеле булганнан соң, Министрлыкның тиешле таләбен алган көннән башлап 60 көн эчендә федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты керемenә кире кайтарылырга тиеш.

13. Субсидия бирү турында килешүләрдә каралган очракларда, хисап финанс елында файдаланылмый калган субсидияләр хисап елыннан соң килә торган елның 1 февраленә кадәр федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты керемenә субсидияләр алучылар тарафыннан кире кайтарылырга тиеш.

14. Әлеге Тәртипнең 12 һәм 13 пунктларында күрсәтелгән акчаларны федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты керемenә үз ихтыяры белән кайтарудан баш тартылган очракта, алар законнар нигезендә мәҗбүри рәвештә түләттерелергә тиеш.

15. Министрлык һәм (яки) дәүләт финанс контроле органы авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә субсидияләр бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлешен законнарда билгеләнгән тәртиптә тикшерә.

16. Тапшырылган документларның дөреслеге өчен җаваплылык законнар нигезендә Программада катнашучыларның җитәкчеләренә йөкләнә.

17. Бюджет акчаларының максатка ярашлы кулланылышын Министрлык тикшереп тора.

2015 елның 8 сентябрендәге
210-2/пр номерлы
ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы боерыгына
3 нче кушымта

“2015 – 2017 елларга Татарстан Республикасында ит өчен терлек үрчетүне үстерү” ведомство максатчан икътисадый әһәмиятле региональ программасын гамәлгә ашыруда катнашучы авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә субсидияләр бирү турында

**КИЛЕШҮ №____**

Казан ш. «____»____________2015

Бер яктан Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы исеменнән, алга таба “Министрлык” дип аталачак, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы мәсьәләләре” 2005 елның 6 июлендәге 316 номерлы карары белән расланган Нигезләмәгә таянып эшли торган Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – министр Әхмәтов Марат Готыф улы һәм икенче яктан

______________________________________________________________
(субсидияләр алучыларның исемнәре, ИНН)

исеменнән, алга таба “Субсидия алучы” дип аталачак, ____________________ нигезендә эшли торган

______________________________________________________________,
(Ф.И.А.и.)

барысы бергә “Яклар” дип йөртеләчәк, “2015 – 2017 елларга Татарстан Республикасында ит өчен терлек үрчетүне үстерү” ведомство максатчан икътисадый әһәмиятле региональ программасын гамәлгә ашыруда катнашучы авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә, крестьян (фермер) хуҗалыкларына, индивидуаль эшкуарларга 2015 елда субсидияләр бирү тәртибе нигезендә түбәндәгеләр турында әлеге Килешүне төзеделәр:

## 1. КИЛЕШҮ ПРЕДМЕТЫ

1.1. Министрлык әлеге Килешү һәм Министрлык боерыгы белән расланган “2015 – 2017 елларга Татарстан Республикасында ит өчен терлек үрчетүне үстерү” ведомство максатчан икътисадый әһәмиятле региональ программасын гамәлгә ашыруда катнашучы авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә, крестьян (фермер) хуҗалыкларына, индивидуаль эшкуарларга 2015 елда субсидияләр бирү тәртибе нигезендә Субсидия алучыга ит бирә торган токымнарга караган мөгезле эре терлекне үрчетү буенча фермаларны һәм фидлотларны (ачык симертү мәйданнарын) төзү, реконструкцияләү, модернизацияләү, электр тапшыргыч линияләр үткәрү, су

белән тәэмин итү линияләре һәм аларга бару юлларын салу, ит бирә торган токымнарга караган мөгезле эре терлекне үрчетү өчен технологик җиһаз һәм азык хәзерләү техникасын сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидияләр бирергә йөкләмә ала.

## 1. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

2.1. Субсидияләр бирү “2015 елга, 2016 һәм 2017 еллар план чорына федераль бюджет турында” 2014 елның 1 декабрендәге 384-ФЗ номерлы Федераль законда, “2015 елга, 2016 һәм 2017 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында” 2014 елның 27 ноябрендәге 107-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм Министрлыкка расланган бюджет йөкләмәләре лимитлары чигендә башкарыла.

2.2. Субсидияләр бирү максатлары ит бирә торган токымнарга караган мөгезле эре терлекнең баш санының 2015 елның 31 декабренә артуын тәэмин итә торган икътисадый һәм технологик шартлар тудырудан; ит җитештерү күләмнәрен арттырудан гыйбарәт.

## 3. СУБСИДИЯЛӘР БИРҮ ШАРТЛАРЫ

3.1. Субсидияләр алу өчен Субсидия алучы Министрлыкка Тәртипнең 7-8 пунктларында каралган документлар тапшыра.

3.2. Субсидияләр Субсидия алучыга Субсидия алучылар милкендә һәм (яки) аренда шартларында ит бирә торган махсус һәм катнаш мөгезле эре терлекнең баш саны булу шарты үтәлгәндә бирелә.

## 4. ЯКЛАРНЫҢ ХОКУКЛАРЫ ҺӘМ БУРЫЧЛАРЫ

4.1. **Министрлык:**

4.1.1. Әлеге Килешүнең һәм Тәртипнең нигезләмәләрендә каралган очракларда субсидияләр бирүне туктатырга, туктатып торырга яки аларның зурлыгын (күләмен) киметергә (кисәргә) хокуклы.

4.1.2. Ит бирә торган токымнарга караган мөгезле эре терлекне үрчетү буенча фермаларны һәм фидлотларны (ачык симертү мәйданнарын) төзү, реконструкцияләү, модернизацияләү, электр тапшыргыч линияләр үткәрү, су белән тәэмин итү линияләре һәм аларга бару юлларын салу, ит бирә торган токымнарга караган мөгезле эре терлекне үрчетү өчен технологик җиһаз һәм азык хәзерләү техникасын сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидияләр бирү шартларын үтәргә хокуклы.

4.1.3. Субсидияләр алучыларның субсидияләр алу өчен кирәкле документларын тикшерергә хокуклы.

4.1.4. Субсидия алучыга Субсидия алучының Килешүдә каралган йөкләмәләрен үтәүгә бәйле мәсьәләләр буенча консультацияләр бирергә.

4.1.5. Субсидияләр биргән вакытта куелган шартлар Субсидия алучы тарафыннан бозылган очракта, алынган субсидияләрне кире кайтаруны таләп итәргә хокуклы.

4.2. **Субсидия алучы түбәндәгеләрне үтәргә йөкләмә ала:**

4.2.1. Әлеге Килешүгә 1 нче кушымтада күрсәтелгән субсидия бирү нәтиҗәлелеге күрсәткечләрен тапшыра һәм аларның үтәлешен тәэмин итә.

4.2.2. Әлеге Килешүгә 2 нче кушымтада күрсәтелгән форма буенча субсидия бирү нәтиҗәлелеге күрсәткечләренә ирешү турында хисапны билгеләнгән срокта тапшыра.

4.2.3. Иң күбе өч эш көненә тигез срокта язма рәвештә Министрлыкка түбәндәгеләр турында хәбәр итә:

карар кабул ителгән көннән алып бетерелү яки үзгәртеп төзелү турында;

арбитраж суд тарафыннан билгеләмә чыгарылган көннән башлап “Бөлгенлек (банкротлык) турында” 2002 елның 26 октябрендәге 127-ФЗ номерлы Федераль законда каралган банкротлык турындагы эштә күреләә торган процедураларны башлау турында;

карар кабул ителгән көннән соң адрес (урнашу урыны) үзгәрү турында.

4.2.4. Алынган субсидияләрне аларны бирүнең Тәртиптә билгеләнгән максатлары һәм шартлары бозылу, субсидияләрнең максатчан билгеләнеше буенча файдаланылмавы һәм (яки) дөрес булмаган белешмәләр һәм документлар тапшырылу очраклары билгеле булу буенча Министрлыкның тиешле таләбен алган көннән башлап 60 көн эчендә федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтара.

4.2.5. Хисап финанс елында файдаланылмый калган субсидияләрне хисап елыннан соң килә торган елның 1 февраленә кадәр федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтара

4.2.6. Министрлыкка һәм дәүләт финанс контроле органнарына аларның субсидияләр алучының субсидияләр бирү шартлары, максатлары үтәлешен тикшерүенә ризалык бирә.

## 5. БӘХӘСЛӘРНЕ ХӘЛ ИТҮ

5.1. Килешүнең Яклары Килешү буенча (һәм/яки аңа бәйле рәвештә) барлыкка килә торган бәхәсләрне һәм аңлашылмаучанлыкларны Яклар арасында сөйләшүләр үткәреп хәл итү өчен барлык чараларны да күрәләр.

5.2. Килешүнең Яклары арасында Килешү буенча (һәм/яки аңа бәйле рәвештә) барлыкка килү ихтималы булган барлык бәхәсләр һәм аңлашылмаучанлыклар, әгәр алар сөйләшүләр үткәреп хәл ителмәсә, Татарстан Республикасы Арбитраж судында каралырга тиеш.

## 6. ЯКЛАРНЫҢ ҖАВАПЛЫЛЫГЫ

6.1. Яклар әлеге Килешү буенча үз йөкләмәләрен үтәмәгән яки тиешенчә үтәмәгән очракта Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы

законнары һәм әлеге Килешү шартлары нигезендә җавап тоталар.

6.2. Субсидия алучы Министрлыкка тапшырыла торган белешмәләрнең дөреслеге, тулылыгы һәм үз вакытында тапшырылыуы һәм Килешүдә билгеләнгән шартларның үтәлеше өчен җаваплы була.

6.3. Субсидия алучы бирелгән субсидияләрне Министрлык таләбе буенча әлеге Килешүнең 4.2.2, 4.2.3. пунктчаларында каралган срокта һәм нигезләр буенча кире кайтармаган очракта, түләү вакыты чыкканнан соңгы һәр календарь көнгә бурыч суммасының 0,5% күләмендә неустойка (пеня) исәпләнә.

## 7. БАШКА ШАРТЛАР

7.1. Әлеге Килешүгә барлык үзгәрешләр, өстәмәләр, әгәр алар язма рәвештә башкарылган һәм ике Якның да моңа вәкаләтләре булган вәкилләре тарафыннан имзаланган булсалар, дөрес булалар һәм аның аерылгысыз өлешләре булып торалар.

7.2. Әлеге Килешү ике нөсхәдә төзелде, алар бертигез юридик көчкә ия.

7.3. Әлеге Килешү ике Якның да кул куярга вәкаләтләре булган вәкилләре тарафыннан имзаланган вакыттан алып 2015 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

## 8. ЯКЛАРНЫҢ ЮРИДИК АДРЕСЛАРЫ ҺӘМ ТҮЛӘҮ РЕКВИЗИТЛАРЫ

Министрлык:
Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы
һәм азык-төлек министрлыгы
420014, Татарстан Республикасы,
Казан ш., Федосеевская ур., 36 нчы й.
р/с 40101810800000010001
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИЛЛИ
БАНКЫНЫҢ КАЗАН ШӘҺӘРЕ БҮЛЕГЕ
Татарстан Республикасы буенча УФК
(Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы
һәм азык-төлек министрлыгы,
04112001090)
ИНН 1654019555
КПП 165501001
ОГРН 1021602854580

Субсидия алучы:

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
урынбасары – министр
______________________М.Г. Әхмәтов

Җитәкче
________________Ф.И.А.и.

2015 елның ________________төзелгән

Килешүгә 1 нче кушымта

## 2015 елга субсидия бирү нәтиҗәлелеге күрсәткечләре

| Күрсәткечнең исеме | Исәп берәмлеге | Күрсәткечнең зурлыгы |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| Ит бирә торган махсус токымнарга караган мөгезле эре терлекнең баш саны (артым кимендә 3 процент) | баш | |
| шул исәптән ит бирә торган махсус токымнарга караган сыерлар (артым кимендә 3 процент) | баш | |
| Ит бирә торган катнаш терлекнең баш саны (артым кимендә 3 процент) | баш | |
| шул исәптән катнаш терлек сыерлары (артым кимендә 3 процент) | баш | |
| Ит бирә торган һәм катнаш терлекне иткә җибәрү өчен тере авырлыгында җитештерү (артым кимендә 3 проңент) | тонна | |

Җитәкче ________________ ____________________________
(булган очракта мөһер) (Имза) (Имзага аңлатма)

Килештерелде

ТР Авыл хуҗалыгы һәм
азык-төлек министрлыгының
терлекчелек тармакларын
үстерү бүлеге башлыгы ________________ ____________________________
(Имза) (Имзага аңлатма)

ТР Авыл хуҗалыгы һәм
азык-төлек министрлыгының
терлекчелек тармакларын
үстерү бүлегенең ит җитештерү
секторы мөдире ________________ ____________________________
(Имза) (Имзага аңлатма)

2015 елның _________________төзелгән
Килешүгә 2 нче кушымта

Субсидияләр алучылар тарафыннан тутырыла
Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына
2015 елның 1 мартыннан соңга калмыйча тапшырыла

## 2015 елга субсидияләр бирү нәтиҗәлелеге күрсәткечләренә ирешү турында хисап <*>

________________________________________________
(авыл хуҗалыгы товарларын житештерүченең исеме)

---
<*> федераль дәүләт статистика күзәтчелегенең 24-СХ номерлы формасы буенча агымдагы елга кадәрге ел өчен терлекчелек торышы турында белешмәнең күчермәсен кушымта итеп теркәп

| Күрсәткечнең исеме | Исәп берәмлеге | 2015 елга субсидия бирү турында килешүдә билгеләнгән күрсәткечнең зурлыгы | 2016 елның 1 гыйнварына күрсәткечнең факттагы зурлыгы | Үтәү нәтиҗәсе | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | исәп берәмлекләрендә | % |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| Ит бирә торган махсус токымнарга караган мөгезле эре терлекнең баш саны | баш | | | | |
| шул исәптән ит бирә торган махсус токымнарга караган сыерлар | баш | | | | |
| Ит бирә торган катнаш терлекнең баш саны | баш | | | | |
| шул исәптән катнаш терлек сыерлары | баш | | | | |
| Ит бирә торган һәм катнаш терлекне иткә җибәрү өчен тере авырлыгында житештерү | тонна | | | | |

Житәкче __________________ ____________________________
(булган очракта мөһер) (Имза) (Имзага аңлатма)

Баш икътисадчы __________________ ________________________
(Имза) (Имзага аңлатма)

Баш зоотехник __________________ ________________________
(Имза) (Имзага аңлатма)

2015 елның 8 сентябрендәге 210-2/пр номерлы
ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы боерыгына
4 нче кушымта

Форма

**“2015 – 2017 елларга Татарстан Республикасында ит өчен терлек үрчетүне үстерү” ведомство максатчан икътисадый әһәмиятле региональ программасын гамәлгә ашыруда катнашучыларга ит бирә торган мөгезле эре терлек токымнарының баш саннары милектә һәм (яки) аренда шартларында булу турында белешмә**

(2015 елның 01 ___________ торышы буенча узган ай өчен)

Авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүченең исеме
Татарстан Республикасы ____________________________________________
____________________________________________

Ит бирә торган терлекнең токымы (токымнары) _______________________
(әгәр хуҗалыкта катнаш терлек үрчетелсә, нигез токымнары күрсәтелә)

| № т/б | Күрсәткечләрнең исеме | Исәп берәмлеге | Барлыгы | шул исәптән | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | чиста токым | катнаш |
| 1 | Милектә булган ит бирә торган токымнарга караган мөгезле эре терлекнең баш саны | баш | | | |
| 1.2 | шул исәптән сыерлар | баш | | | |
| 2 | Арендадагы ит бирә торган токымнарга караган мөгезле эре терлекнең баш саны | баш | | | |
| 2.1 | шул исәптән сыерлар | баш | | | |

Җитәкче _______________ _______________________
(булган очракта мөһер) (имза) ФИАи

Баш икътисадчы _______________ _______________________
(имза) ФИАи

Татарстан Республикасы Авыл
хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының
Татарстан Республикасы _________________
муниципаль районында
Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек
идарәсе башлыгы _______________ _______________________
(имза) ФИАи

Баш бухгалтер _______________ _______________________
(мөһер) (имза) ФИАи

2015 елның 8 сентябрендәге 210-2/пр номерлы
ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы боерыгына
5 нче кушымта

Форма

“2015 – 2017 елларга Татарстан Республикасында ит өчен терлек үрчетүне үстерү” ведомство максатчан икътисадый әһәмиятле региональ программасын гамәлгә ашыруда катнашучы авыл хуҗалыгы товарларын житештерүчеләргә федераль бюджет акчалары исәбеннән бирелергә тиешле субсидияләр турында исәп-хисап белешмә
________________________________буенча
(субсидия алучының исеме, муниципаль районның исеме)

| Программаны гамәлгә ашыра башлаудан алып тотылган чыгымнарның бер өлеше кайтарыла торган күләме | Чыгымнар суммасы, сум | Субсидия ставкасы | Субсидияләр суммасы, сум |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| ит бирә торган токымнарга караган мөгезле эре терлекне үрчетү буенча фермаларны һәм фидлотларны төзү, реконструкцияләү, модернизацияләүгә | | башкарылган эшләр күләменнән 20% | |
| ит бирә торган токымнарга караган мөгезле эре терлекне үрчетү өчен технологик җиһаз һәм азык хәзерләү техникасын сатып алуга | | сатып алынган җиһаз һәм азык хәзерләү техникасы бәясеннән 20% | |
| Барлыгы: | | Х | |

Белешмәләрнең дөреслеген раслыйм:
Субсидия алучы оешманың җитәкчесе

Баш бухгалтер ________________ (имза) ________________ ФИАи
(булган очракта мөһер)
________________ (имза) ________________ ФИАи

Татарстан Республикасы
____________ районы башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлеге башлыгы ________________ (имза) ________________ ФИАи

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының
Татарстан Республикасы
__________________
муниципаль районында
Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы ____________ (имза) ________________ ФИАи
Баш бухгалтер
(мөһер) ____________ (имза) ________________ ФИАи

ТР Премьер-министры урынбасары –
ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры ____________________М.Г.Әхмәтов
(мөһер) (имза)

2015 елның 8 сентябрендәге 210-2/пр номерлы
ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы боерыгына
6 нчы кушымта

Форма

“2015 – 2017 елларга Татарстан Республикасында ит өчен терлек үрчетүне үстерү” ведомство максатчан икътисадый әһәмиятле региональ программасын гамәлгә ашыруда катнашучы авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән бирелергә тиешле субсидияләр турында исәп-хисап белешмә

____________________________________________________буенча
(субсидия алучының исеме, муниципаль районның исеме)

| Программаны гамәлгә ашыра башлаудан алып тотылган чыгымнарның бер өлеше кайтарыла торган күләме | Чыгымнар суммасы, сум | Субсидия ставкасы | Субсидияләр суммасы, сум |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| ит бирә торган токымнарга караган мөгезле эре терлекне үрчетү буенча фермаларны һәм фидлотларны төзү, реконструкцияләү, модернизацияләүгә | | башкарылган эшләр күләменнән 55% | |
| ит бирә торган токымнарга караган мөгезле эре терлекне үрчетү өчен технологик җиһаз һәм азык хәзерләү техникасын сатып алуга | | сатып алынган җиһаз һәм азык хәзерләү техникасы бәясеннән 55% | |
| Барлыгы: | | Х | |

Белешмәләрнең дөреслеген раслыйм:
Субсидия алучы оешманың җитәкчесе ____________ ____________
(имза) ФИАи

Баш бухгалтер
(булган очракта мөһер) ____________ ____________
(имза) ФИАи

Татарстан Республикасы
____________ районы башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлеге башлыгы ____________ ____________
(имза) ФИАи

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Татарстан Республикасы
____________
муниципаль районында Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы ____________ ____________
(имза) ФИАи

Баш бухгалтер
(мөһер) ____________ ____________
(имза) ФИАи

ТР Премьер-министры урынбасары –
ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры
(мөһер) __________________М.Г.Әхмәтов
(имза)